Хатыйп Миңнегулов —

Казан федераль университеты профессоры

# Кыйтгаларны тоташтыручы Уралда

Ничә төрле кадерле ташлы таулар,
Көмеш, алтын, бакыр, кургашлы таулар.
Аерган Шәрык вә Гаребкә кыйтгаларны,
Кавыштырган үз өстендә аларны..

*Дәрдемәнд.*

Мәзәк китеп карап тордым
Нәни генә кырмыскага:
Йөк күтәреп чыгып бара
Азиядән Европага.

*Мостай Кәрим.*

Адәм баласы искедән аерыла, яңага күнегә алмыйча иза чигә. Миңа Рәчәйнең «Төньяк башкаласы»нда элек тә, хәзер дә күп мәртәбәләр булырга, хәтта анда берничә айлап яшәргә дә туры килде. Шунда бер нәрсәгә игътибар иттем: өлкән буын бу шәһәрне күбрәк Питер, Петербург дип атавын дәвам итте; ә совет чорында балигъ булганнар өчен ул Ленинград иде. Узган гасыр азагында кала исеме алышынды. Хәзер исә бу шәһәр яшьләр өчен Питер, ә өлкәннәргә Ленинград рәвешендә кабул ителә. Хәзерге Екатеринбург белән дә шундый ук хәл. Өлкән буынның бер вәкиле булган минем өчен ул һаман да Свердловск ( чын татарча — Сверлау) булып калуында дәвам итә.

Ике кыйтга чигендә урнашкан Екатеринбург — Сверлау шәһәре һәм өлкәсе — элек-электән илнең иң мөһим сәнәгать төбәкләреннән берсе. Биредәге атаклы «Уралмаш»лар, «Демидов», Түбән Тагил заводлары мәктәп елларыннан ук күңелгә кереп калган. Бу җирләрнең табигате, тигезлекләре һәм таулары, яфраклы һәм ылыслы урманнары, җәйрәп яткан күл-елгалары, шактый озын-озак чыгышлы туннельләре поездда һәм машинада барганда да сине әсир итәрлек. Сверлау — зур мәдәни, фәнни һәм мәгърифәти үзәк тә. Андагы атаклы опера һәм балет театры (100 еллык тарихы бар!), консерватория, университет, гыйльми үзәк (боларның барысы да «Урал»

исемен йөртә), музейлар Рәчәйдә генә түгел, чит мәмләкәтләрдә дә мәгълүм. Биредә күпсанлы китаплар, гәҗит-журналлар чыгып тора, ил һәм дөньякүләм чаралар даими уздырыла.  Менә минем кулда «Культура Урала» журналының соңгы саннары. Бу затлы  мәҗмуганы актарганда бу төбәктә мәдәни-сәнгати тормышның кайнап торуына, байлыгына, югарылыгына янә бер мәртәбә инанасың. Күп кенә мәшһүр шәхесләрнең биредән чыгуы да, күрәсең, юкка гына түгел. Болар арасында Рәчәйнең тәүге президенты Борис Ельцин да бар. Шунысын да искәртик: сверлаулылар хәзер дә үз якташларын хөрмәт итәләр. Урал федераль университетына Б. Н. Ельцин исеме бирелү үзе генә дә күп нәрсә хакында сөйли.

Миллион ярымлап халык яшәгән Екатеринбург (Кәтеренә каласы) — Свердловск өлкәсенең генә түгел, гомумән бөтен Уралның мәркәзе дә. Башкалалык аның мәдәни, интеллектуаль тормышында да, зур-зур бина-ташпулатларында, масштаблы корылышында да ачык күренә. Узган гасыр ахырларында губернатор Э. Россель күтәреп чыккан «Урал республикасы» төзү идеясенең дә, мөгаен, объектив җирлеге бар.

Урал, шул исәптән хәзерге Сверлау төбәге  дә татар өчен үз һәм якын. Безнең әби-бабаларыбыз, мондагы угро-фин, башкорт кавемнәре кебек, биредә элек-электән җирле халык буларак гомер кичергән. XIII—XV йөзләрдә Урал Алтын Урданың мөһим бер кыйсемен тәшкил иткән. Ул таркалгач, хәзерге Сверлау җирләре Себер, өлешчә Чердынь ханлыклары составына керә. Мәскәүнең Себергә ясалган походлары да, нигездә, шушы тирәләрдән уза. Рәчәй империягә әверелгәч, Урал, Себердәге кавемдәшләребез янына Идел-йорттан күчеп-качып китүчеләр дулкыны һич өзелеп тормый. Бу процессның әле соңгы дәвердә дә тукталганы юк. Минем туган яктан (ягъни Зәй, Сарман төбәкләреннән), мин белгән кешеләрнең, хәтта күршеләремнең дә Сверлау тарафына күчеп яшәве мәгълүм. Хәзерге вакытта Уралдагы ике миллионнан артык татарның 200 йөз меңгә якыны Сверлау өлкәсендә гомер кичерә. (Шуның дүрттән береннән артыгы Екатеринбург шәһәрендә.) Калганнары башка шәһәрләрдә һәм Ачыт, Артын,

Красноуфим, Түбән Серга һ. б. районнарында яши.

Кавемдәшләребез оешып яшәгән башка төбәкләрдәге кебек, биредә дә элек-электән үк мәктәп-мәдрәсәләрнең, мәчет-мәхәлләләрнең, мәдәни учакларның булуы, татар китабының, басма сүзенең таралуы мәгълүм. Милли-мәдәни тормыш аеруча узган гасырның беренче яртыларында көчле була. Өлкәнең авыл-шәһәрләрендә (шул исәптән Сверлауның үзендә дә) иллегә якын татар мәктәбе була. 1919—1941 елларда татар-башкорт педтехникумының эшләве мәгълүм. Сверлау совет-партия мәктәбендә, педагогия институтында махсус татар бүлекләре яши. Урал татар театры эшли (сәнгать җитәкчесе — Исхак Һилалов). 1918—1932 елларда 106 исемдә татарча китап басыла (гомуми тиражы 487 565). Сверлау төбәгендә 1917 ел инкыйлабыннан соң татар телендә берничә дистә гәҗит-журнал нәшер ителә: «Урал тавышы», «Коммунист» (1925 елдан — «Сабан һәм Чүкеч»), «Социализм юлы» (биредә 30 нчы елларда Хатип Госман да эшләп ала), «Алмашка», «Яшь коммунар», «Урал мәгариф», «Шәпи агай» (1929— 1927) һ. б. Кызганыч ки, узган гасырның урталарында һәм икенче яртысында Сверлау төбәгендә милли тормыш шактый зәгыйфьләнә, урыслашу көчәя. Бу процесс хәзер дә дәвам итә. Әгәр дә 1989 елда өлкәдә туган телен белүче татарлар 76 процент булса, 2010 елда бу күрсәткеч 44 процентка кадәр төшә. Күрше-тирәләрдә дә бу саннар шактый шомлы. 2010 елгы җанисәп мәгълүматлары күрсәтүенчә, үз туган телендә сөйләшүче татарлар саны Пермь краенда 76% (87606 кеше), Курган өлкәсендә 60% (10200), Чиләбе төбәгендә 45% (81486 кеше). [«Саф чишмә» гәҗите. — ноябрь, 2012]. Күрәсез: болар арасында Сверлау өлкәсе «иң алдынгы» урынны били. Милли яшәештә туган катлаулы вәзгыять Сверлау төбәге татарларын да уйланырга, билгеле бер чаралар, гамәлләр кылырга мәҗбүр итте. Бу өлкәдә соңгы ике дистә ел эчендә шактый гына эшләр башкарылды. М. Гафури исемендәге татар-башкорт культура җәмгыяте (оештыручысы һәм рәисе Сөфхәт Надиров), милли-мәдәни автономия, мәдәни, дини, яшьләр, спорт оешмалары, якшәмбе мәктәпләре эшли башлады. Өлкәдә йөзгә якын мәчет,

гыйбадәт йортлары бар.

Сирәк булса да, татарча радио-телевидение тапшырулары оештырыла. 2001 елдан бирле айлык «Саф чишмә» гәҗите чыгып килә. (Мөхәррире — Фәвия ханым Сафиуллина). Сирәк булса да «Уралтау» да басыла. Екатеринбургта 1996 елдан Татарстанның бу өлкәдәге һәм Уралдагы вәкиллеге нәтиҗәле генә эшли. Аның белән әүвәл Р. Бикбов, хәзер Ринат әфәнде Садриев җитәкчлек итә. «Татарстан-Яңа гасыр» телерадиокомпаниясенең Екатеринбургтагы корпункты (Әлфия Габдушева, Салават Кыямов) инде 5 ел буена Уралдагы милли тормышны яктыртуда, оештыруда саваплы гына гамәлләр кыла.

Шунысын да искәртик: күп кенә күренекле милләттәшләребезнең эшчәнлеге Сверлау төбәге белән бәйле. Химаяче сыйфатында татар рухи тормышына сизелерлек өлеш керткән бертуган Агафуровларның эшчәнлеген хәзер дә биредәге зыялыларыбыз еш телгә ала. Аларның Екатеринбург үзәгендәге йорт-корылмалары хәзер дә саклана. Атаклы җырчы, күп төрле бүләкләр иясе Нияз Даутов (1913—1986) 1953 елда Урал консерваториясен тәмамлый, Мәскәүнең атаклы театрларында чыгыш ясый. 1943—1956, 1960—1965 елларда — Свердловск каласындагы опера һәм балет театрының солисты һәм режиссеры. 1965—1975 елларда Чиләбе театрында эшли. Искиткеч талантлы һәм югары профессиональ осталыкка ия булган бу зат М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрының да баш режиссеры булып торды, Казан консерваториясендә опера җырчылары тәрбияләүгә дә үзеннән зур өлеш кертте. [Н. Даутовның тууына бу елның 23 сентябрендә 100 ел тула. Бу истәлекле датаны Казанда гына түгел, ә ул эшләгән Свердлау, Чиләбе калаларында да зурлап уздыру — милләттәшләребезнең әхлакый бурычы!]. Дәүләт эшлеклеләре Сәхибгәрәй Сәетгалиев һәм Кашаф Мохтаров, армия генералы Мәхмүт Гәрәев һәм башка билгеле затлар да берара бу төбәктә яшәп, эшләп алалар. Атаклы гимнастлар Әлфия һәм Лилия Нәҗметдиновалар һәм тормышлары, һәм бөтен яшәешләре белән Сверлау белән бәйле. Күпләгән конкурслар лауреаты, Россиянең

атказанган артисты, педагог, балалайкада уйнауның тиңсез остазы Шәүкәт Әмиров Урал консерваториясен тәмамлый, хәзер дә шунда профессор булып эшли, милли-мәдәни чараларны оештыруга һәм үткәрүгә үзеннән зур өлеш кертә. (1990—1999 елларда ул Казан консерваториясендә дә укытты, кафедра мөдире, проректор вазыйфаларын башкарды).

Минем өчен Сверлау яклары билгеле бер дәрәҗәдә күптәннән таныш. Анда болай да берничә мәртәбә булганым, поезд белән дә аның аша күп тапкырлар узып киткәнем бар. Хәтта бер баруда ике кыйтга чигендә туктап, кызык өчен бер аягым белән Аурупада, икенчесе белән Азиядә басып торуымны да хәтерлим. 1968 елның җәендә студентлар белән Чиләбе өлкәсенә фольклор экспедициясенә барганда биредә туктап, көне буе шәһәрнең истәлекле урыннарын карап йөргән идек. Аеруча өлкә музеендагы зиннәтле ювелир эшләнмәләр, затлы савыт-сабалар, табигый байлыклар хәтергә уелып калган. 2005 елның февраль башларында Сверлау өлкәсенең татар теле һәм әдәбияты укытучылары белән атналык семинар уздырган идем. Аны ул вакыттагы өлкә мәгариф идарәсе методисты, бик тә татар җанлы, татар-башкортның яраткан шагыйре Әнгам Атнабаевның якташы Зәйтүнә ханым Шәймөхәммәтова оештырган иде. Тимер юл вокзалы каршысындагы «Свердловск» кунак йортында янгын чыгып, төн уртасында кышкы салкында урамга йөгереп чыгу да истә калган. Ерак булмаган Пышма шәһәренә барып, андагы бик матур, яңа мәчетне дә карап кайткан идек.

Сверлаудагы милли оешмалар, зыялыларыбыз, Татарстан вәкиллеге күп төрле иҗтимагый, гыйльми, мәдәни чараларны еш уздырып тора. Менә шундыйларның берсенә (ул 18—19 январьда булды) мин һәм Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары, күренекле драматург Данил әфәнде Салихов та чакырылган идек. Үзәккә татар китабы мәсьәләләре куелган бу чара, чынлыкта, күптармаклы, иҗтимагый-мәдәни һәм мәдәни тормышта шактый яңгыраш алган мөһим бер вакыйга булып чыкты. Аның эшендә, күпләгән милләттәшләребез белән берлектә, башка халык вәкилләре, галимнәре, иҗат әһелләре, хакимият хезмәткәрләре (шул исәптән өлкә

мәдәният министры, губернатор аппараты вәкиле) катнашты. Бу чара матбугатта, радио-телевидениедә дә яктырылыш тапты, һәм ул еш кына «Татар мәдәнияте көннәре» дигән бәя дә алды.

Әүвәл безне Татарстанның Уралдагы вәкиле Ринат әфәнде Садриев кабул итте. Анда төбәктәге милли-мәдәни эшләрнең торышы хакында җитди сөйләшү булды. Ринат әфәнде элекке хәрби — иҗтимагый-сәяси, икътисади мәсьәләләрдән яхшы хәбәрдар; эшкуар да. Энергияле. Заманча кеше. Ныклап татарча сөйләшергә дә өйрәнеп килә. Ул безнең белән бөтен чараларда катнашты, оештырып йөрде, берничә мәртәбә чыгыш та ясады.

Алга таба безне Урал университетына алып киттеләр. 90 елдан артык тарихы булган бу уку йорты илдәге иң күренекле һәм зур университетлардан берсе хисаплана. Соңгы елларда ул федераль статусын ала. Мин «Уральский государственный университет в биографиях» белешмәсенең соңгы — өченче басмасын (2010 — 614 бит) актарып чыктым. Бик тә күренекле галимнәр эшләгән һәм эшли. Әмма татар фамилияле гыйлем әһелләре күзгә сирәк ташлана. Биредә безне физика-математика фәннәре докторы, Россия фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы Владимир Евгеньевич Третьяков бик җылы кабул итте. Ул 1993—2006 елларда университет ректоры булган, хәзер бу уку йортының президенты. Гуманитар фәннәрдән, милли мәсьәләләрдән хәбәрдар. Бу мөхтәрәм зат шушы ук университетның конференц-залында уздырылган семинарда да катнашты, тәбрикләү сүзе белән чыкты. Урал федераль университеты, М. Гафури җәмгыяте, Татарстан вәкиллеге тарафыннан оештырылган бу семинарда (ул урыс телендә барды) галимнәр, әдипләр, журналистлар, мәдәният әһелләре, хакимият вәкилләре катнашты. Җыелган халык шактый хәзерлекле, югары дәрәҗәле иде. Мәгълүм ки, Россия Язучылар берлегенең Урал (Екатеринбург) төбәге шактый күп санлы әдипләрне берләштерә. Аларның дистәгә якыны семинарга да килгән иде. Шундыйларның берсе — күпкырлы талант иясе, шагыйрь, прозаик һәм драматург, төрле бүләкләр иясе (шул исәптән «Поэзия Академиясе академигы») Юрий Конецкий белән мин якыннан да таныштым. Ул миңа

«Московский Парнас» нәшриятында 2006 елда дөнья күргән затлы бизәлгән өч томлык әсәрләрен бүләк итте. Анда кызыклы,  оригиналь шигъри, чәчмә әсәрләр, драма һәм либретто текстлары урнаштырылган. Китапта инглиз, әрмән, авар, азәрбайҗан, кытай, украина, төрекмән һәм кайбер башка халыкларның шигъриятеннән тәрҗемәләр дә бар. Юрий Конецкий башкорт шагыйре, татар укучыларына да яхшы таныш булган Риф Тойгының да 10 шигырен русчага күчергән. Татар шагыйре Гани Зарифның  өч шигъри парчасы да тәрҗемәдә матур гына яңгыраш алган. Семинарны Урал федераль университеты мөгаллиме, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Рафаил Лотфулла улы Исхаков алып барды һәм төп докладларның берсен дә ул ясады. «Татар китабының тарихи тәҗрибәсе һәм заман», «Бөтендөнья татар конгрессының бишенче корылтае йомгаклары», «Хәзерге әдәби процесс һәм басма китап», «Күпмилләтле Урал әдәбияты» кебек проблемалар семинарның көн тәртибенә кертелгән иде. Беренче мәсьәлә буенча төп докладны без фәкыйрегезгә ясарга туры килде. Мин тарихи-халыкара контекстта татарның рухи мирасы, кульъязма һәм басма китаплары, аерым мөһим милли мәсьәләләр хакында сөйләдем. Доклад уңай кабул ителде, күп кенә сорауларга җаваплар бирелде. Гомумән, семинар җанлы барды, бәхәсләр дә булды. Баксаң, Россия фәннәр академиясе Урал бүлегенең тарих һәм археология Институты Урал әдәбияты тарихын яза икән. Шуның дүртенче томын Уралдагы милли әдәбиятларга багышларга ниятлиләр. Бу эшнең башында торучы филология фәннәре докторы, профессор Елена Константиновна Созина тарафыннан хезмәтнең план-проспекты да семинарда катнашучыларга тәкъдим ителгән иде. Анда удмурт, башкорт, коми, пермяк, ханты, манси, ненец һәм кайбер әдәбиятлар бар. Тик татар сүз сәнгате генә юк. Биредә тәмам «юк» дип әйтү дөрес булмас. Кол Гали һәм Сәйф Сараидан алып Әбелмәних Каргалый, Мәҗит Гафури, Афзал Таһировларга кадәрге төрки-татар әдипләре бары тик «башкорт әдәбияты» исеме астында гына бирелгәннәр. Бу хәлгә, табигый, мин ризасызлыгымны белдердем. Елена ханымга һәм безнең әдәбияттан хәбәрдар булмаган

кешеләргә билгеле хакыйкатьне янә бер аңлатырга туры килде. Әмма минем оппонентым бәхәсне дәвам итте. Аның фикеренчә, татарның асыл ватаны — Татарстан, ул административ-территориаль яктан Уралга түгел, Идел буена керә, республикадан читтәге татарлар — диаспора. Бу мәсьәләгә дә мин үз мөнәсәбәтемне белдердем. Урыс әдәбияты зур мәйданнарны били. Шуңа күрә аны төбәкләп (Себер, Ерак Көнчыгыш, Төньяк, Урал, Идел буе...) өйрәнү фәндә һәм гамәлдә кулланыла. Татар әдәбияты да Евразиянең шактый киң мәйданын били. Татар әдипләренең яртысы диярлек Башкортостаннан, Пермь, Төмән, Оренбур һәм Уралның башка төбәкләреннән. Дәрдемәнд, Ф. Кәрим, М. Җәлил, М. Әмир һәм башка бик күпләр — моның җанлы мисаллары. Ахыр чиктә Елена ханым Созина бу мәсьәләдә аерым башкорт галимнәренең карашларына ияреп буталуын үзе дә таныды. Семинар вакытында дүртенче томга «Уралдагы татар әдәбияты» дигән бүлек кертү турында килешенде. [Казанга кайткач, хезмәттәшләр белән киңәшеп, бу хезмәтне язуга Уфада яшәүче күренекле профессор Раиф әфәнде Әмировның ризалыгын алдык. Рәхмәт төшсен үзенә!]

Семинарда этник чыгышы белән милли, язма теле урысча булган әдипләрне кайсы халык язучысы дип атау хакында да бәхәс кузгалды. Әлбәттә, биредә мәрхүм Туфан Миңнуллин булса, «кем кайсы телдә яза, ул шул телне кулланучы халыкның язучысы» дип кистереп җавап биргән булыр иде. Әмма чынбарлыкта моңа туры килми торганнары да бар. Чыңгыз Айтматов, нигездә, урысча язды. Әмма кыргызның асыл табигатен, яшәешен аның кебек тирән чагылдырган авторлар бик күренми шул. Олжас Сөләйманов, үзебезнең Рөстәм Кутуй, Равил Бохараевларны да, язу телләренә карап, урыс әдибе дип кенә атап булмый. Гомумән, хәзерге глобальләшү чорында дөньяда киң таралган инглиз, испан, француз, урыс телләрендә язучы, әмма башка милләттән булган әдипләр күп. Әмма аларны, язу телләренә карап кына, инглиз яисә испан язучысы дип санау чынбарлыкка хилафлык китерү булыр иде.

Урал федераль университетындагы семинардан соң безне Милли

әдәбиятлар китапханәсенә очрашуга алып кителәр. Ул бик бай, якты, уңайлы. Китапханәдә татар басмалары, Казанда чыгып килүче гәҗит-журналлар да шактый. Китапханә мөдире — урта яшьләрдәге урыс ханымы — үз эшенә бик тә җаваплы карый, шәһәрдәге милли оешмалар, шул исәптән татар җәмгыятьләре белән дә тыгыз мөнәсәбәттә тора.

Сверлауда булуыбызның икенче көнендә безне өлкә башкаласыннан 130—140 чакрым ераклыктагы Әрәкәйгә (Аракайга) алып бардылар. Урманнар, биек таулар арасында урнашкан уртача гына зурлыктагы бу татар авылы безне үзенең төзек йортлары, нурлы мәчетләре, мәдәният йортлары, аеруча «Сәрдәрия» (Сардария) фольклор ансамбле белән бик җылы каршы алды. Биредә олысы да, кечесе дә җырлый, бии кебек тоелды безгә. Күптөрле конкурс-ярышларда катнашып, лауреат, призлы урыннарны алган бу ансамбль бөтен татар тамашачысына да яхшы таныш. Ул, Казандагы Боз сараенда чыгыш ясап, Бөтендөнья татарларының соңгы корылтаенда катнашучыларны да шаккатырган иде. Ансамбль белән (әгәр дә ир-атлар арасында матурлык, уңганлык конкурсы булса, анда җиңеп чыгарлык) Салават Гобәев җитәкчелек иткән Әрәкәй мәдәният йортында бик тә мәгънәле, кызыклы очрашу булды. Анда Түбән Серга районы хакимият башлыгы Валерий Еремеев тә катнашты һәм чыгыш ясады. Заманында Себер, Тубыл, Оренбург, Пермь, Екатеринбург губерналары составына кереп алган бу төбәктә берничә татар авылы бар(Уфа-Шигир, Абаш, Үрмәкәй, Шөкер, Көнтуган ....). Район башлыгы милли тормышны яхшы белә, татарча да аңлавын әйтте. Аның үзен дә милләттәшләребез хөрмәт итә. 2011 елда Екатеринбургта «Мы частица твоя, Россия, Нижнесергинская земля» дигән гаҗәеп затлы, өлкә-республика җитәкчеләрен дә көнләштерерлек китап-альбом нәшер ителгән. Анда районның күренекле кешеләре дә (мәшһүр җырчы В. Трошин, спортчы В. Глазунов...), тарихы һәм табигате дә, авыл-шәһәрләре дә, милли төрлелеге дә һәм яшәү рәвеше дә чагылыш тапкан. В. Еремеев бу истәлекле басманы безгә дә бүләк итте. Рәхмәт үзенә!

Чын татарча гомер кичерүче әрәкәйлеләр белән очрашудан күңелләр

күтәрелеп, без янә Сверлауга юнәлдек. Биредә шул ук көнне Лавров исемендәге 850 урынлы мәдәният сараенда татар китабына багышланган зур кичә булды. Зал тутырып милләттәшләребез утырган! Араларында өлкә мәдәният министры, губернатор аппараты вәкиле һәм башка рәсми затлар да бар. Сәхнәдә иң әүвәл миңа сүз бирделәр. Аннан Данил Салихов җыр белән (ул бик матур җырлый) сәлам сүзләрен җиткерде, милли хәрәкәттә актив катнашучы берничә кавемдәшебезгә рәсми «Рәхмәт хат»ларын тапшырды. Сөфхәт әфәнде Надировның да чыгышы бик мәгънәле булды һәм җылы кабул ителде. Алга таба кичәнең концерт өлеше башланды. Аны бик матур итеп Фәвия Сафиуллина һәм Хәйдәр Гыйльфанов алып барды. Концерт тамашачылар тарафыннан бик яратып кабул ителде. Әүвәл Сверлауның үз иҗат көчләре (Руслан Ваккасов, Альбина Вахитова, Ш. Әмиров, Хәйдәр...) чыгыш ясады. Екатеринбургта туып үскән, махсус музыка белемле Альбина Вахитова теленең сафлыгы һәм төзеклеге, тавышының матурлыгы, татар җырларын зур осталыкта башкаруы белән аеруча җылы тәэсир калдырды. Хәзер бу талантлы кыз Казанда яши. Концертның шактый өлешен «Казан егетләре»нең чыгышы тәшкил итте. Аларның осталыкларына, халык тарафыннан яратылуларына без янә бер мәртәбә инандык. Кичә беткәч, бу егетләрне күпләгән хатын-кызларның чорнап алуына, алар белән фотога төшүләренә, сөйләшүләренә без Данил белән кызыгып, хәтта бераз көнләшеп тә карап тордык.

Концерт тәмамлангач, татар мәдәни чаралары «Сабантуй» кафесында дәвам итте. Күп кенә зыялыларыбыз (хәтта күренекле татар спортчылары да) катнашкан бу мәҗлестә татарча сөйләм, татар җыр-биюе, милли музыка хакимлек итте. «Сабантуй»дан безне шул ук кичне поездга утыртып озатып җибәрделәр.

Сверлаудагы бер төнебез, ике көнебез бик тә тыгыз, истәлекле булды. Шунысын да әйтик: биредәге милләттәшләребез 18—19 гыйнварда үткән бу чараларга алдан ук ныклап әзерләнгәннәр. Хәтта «Саф чишмә» исемле 74 битлек җыентык та чыгарганнар. (Төзүчесе Р. А. Исхаков). Ул «Саф чишмә»

гәҗитенең чыга башлавына 10 ел, татар басма китабының 290 еллыгына багышланган. Китапта җирле авторларның шигъри, чәчмә әсәрләре, публицистик язмалары урын алган. (Арада урыс телендәге текстлар да бар): Авторлар арасында төрле буын, төрле шөгыль кешеләре, хәтта укучылар да бар. (Данис Бәдретдинов, Сәгъдә Бәшәрова, Винарис Габдрахманов, Резедә Шәрипова, Рафаил Якуп һ.б.). Язмалар арасында милли рухлы, кызыклы гына юллар да күзгә ташлана. Хафиз Галиев «Мифларга параллельләр» шигырен болай төгәлли:

...Ә халкыбыз мифик Прометейдай
Чылбырланмаса да таш кыяга,
Ике башлы бөркет ничә гасыр
Талый аның рухын үз җаена.

Заһид Тимернең «И, Тукай!» шигыре татарның бөек улына хөрмәт, ихтирам хисләре белән сугарылган:

...Күктән йолдыз атылгандай
Ялтырап очты Тукай.
Ядкарь итеп Тукай моңын
Һавада җырлый тургай.
И, Тукай, бөек Тукай,
Син исән кебек, Тукай.

Шәмси Шахмаевның «Татармын мин» шигыре үз халкы өчен горурлану хисе белән сугарылган:

Татар мин, төптән тирәннән,
Тамырым, каным татар.
Телем генә бераз җирле,
Зиһенем, җаным — татар.

Идел буе, Урал, Себер —
Бары да татар иле.
Тумышымнан ишеткән тел —

Әткәм-әнкәмнең теле...

Туган җирем — Уралыма
Татарлыгым уралган.
Уралган да, «Тәфтиләү»не
Җырлап бара җиһаннан.
Татарча монда сайрыйлар
Таңнарда сандугачлар.
Татар телендә серләшә
Урманнарда агачлар.

Татарлыгыма шатланып,
Горурланып яшим мин.
Түбәтәйле, сабантуйлы,
Якты уйлы татар мин...

Үзләренең мөстәкыйль дәүләте булмаган халыкларның милли тормышы барыннан да элек милләтпәрвәр шәхесләрнең эшчәнлегенә, фидакарьлегенә бәйле. Кәтеренә каласына сәфәр вакытында мин моңа янә бер мәртәбә ышандым. Биредәге татарпәрвәр затларның берсе һәм, мөгаен, иң күренеклеседер — Сөфхәт әфәнде Надиров. Ул чыгышы белән мәшһүр Барда якларыннан. Каенавылдан. Мәсгут Имашевның нәселдәше, якташы. Яшьтән үк туган теленә, җыр-моңга гашыйк. Вокал буенча Уфа сәнгать училищесын тәмамлый. Профессиональ җырчы. Филармониядә, академик капеллада эшли. Башка бик күп һөнәрләрне сынап карый. Инде 1977 елдан бирле Сверлауда. Биредәге милли, мәдәни хәрәкәтнең үзәгендә. Ул халкыбыз, аның теле, язмышы өчен яна-көя, шатлана-сөенә. Җиде дистәне тутыруына да карамастан, Сөфхәт әфәнде һаман да лидер — башлап йөрүче. Мин аның фатирындагы шәхси китапханәне күреп шаккаттым. Аңа тиңләшерлек көтепханә, мөгаен, Төмән өлкәсенең Акъяр авылында гомер кичерүче, ветеран укытучылар — Люция һәм Хатыйп Хәбибуллиннарда гына

бардыр. Һәр икесенең дә китапханәләрен бүген үк «Татар китабы музее» итәрлек. Сверлаудагы бер кичебезне без Сөфхәт әфәнде һәм аның ачык йөзле җәмәгате Рәйсә ханымнарда уздырдык. Өй хуҗасы белән Данил әфәнденең бергәләп матур итеп җырлауларына хозурланып утырдым. Үзе бер концерт, үзе бер тамаша! Сөфхәт әфәнденең кызы Дилизә дә Урал консерваториясенең ике бүлеген төгәлләгән музыкант. Фәвия ханым Сафиуллина — Казан арты кызы, финанс-экономика институтын тәмамлаган белгеч — инде күп еллар Сверлауда гомер кичерә. Милли-мәдәни чараларны төп оештыручыларның берсе. Мин аны инде берничә елдан бирле беләм. Ул ачык йөзле, төзек сөйләмле, уңган хатын. Бу тынгысыз зат «Азатлык» радиосының хәбәрчесе дә булып эшләде. Татарча телевизион тапшыруларның оештыручысы һәм алып баручысы да булды. Фәвия ханым 2002 елдан бирле чыгып килүче айлык «Саф чишмә» гәҗитенең дә мөхәррире һәм төп авторы. Бу басмада Урал төбәгенең һәм гомумән татар дөньясының милли тормышы даими чагылыш таба. Әдәби, сәнгати язмаларга да урын бирелә. Хәзерге вакытта Фәвия ханым Татарстан вәкиллегендә дә хезмәт куя.

Сверлау татарларының милли-рухи мәгыйшәтен оештыруга җитди өлеш кертүче шәхесләрнең берсе — Хәйдәр Гыйльфанов. Чыгышы белән Сарман районындагы Рантамак авылынннан. Мин аны инде 35 еллап беләм. Студентлар белән Ульяновск өлкәсенең Кулатка районына 1978 елда барган фольклор экспедициясенә мин аны, укытучысы — музыкант Геннадий Максимов тәкъдиме белән, җырчы буларак алган идем. Бу вакытта Хәйдәрнең Казандагы 10 нчы мәктәп-интернатта укыган чагы. Әле тавышы ныгып җитмәгән. Өстәвенә салкын су эчеп, тамагы да бетеп, берничә концертта җырлый да алмады. Мин аны «артык йөк булып йөрисең»,— дип шелтәләгәнемне дә хәтерлим. Аннан Хәйдәр мәдәният институтына укырга керде. 80 нче еллар башында мин аны Урал якларына оештырылган экспедициягә янә алдым. Монысында инде ул үзенең матур җырлавы белән концертларны бизәп торды. Пермь янындагы Куян авылында (Каяново)

концерттан соң бер фатирда төнлә йокларга яттык. Бервакыт Хәйдәребезнең аһ-ваһ килүенә уянып киттек. Мескеннең йөзләре агарган, нишләргә белми. «Нәрсә бар?» дигәнгә ул, «колакка нәрсәдер керде»,— дип җавап бирде. Шунда минем хәтергә авылда чакта әрлән, йомран оясына су салып, аларны чыгару искә төште дә, Хәйдәрнең авырткан колагына бер олы кашык су җибәрдем. Шуннан нәрсә булды дип сорыйсызмы? Колактан бер олы кара таракан килеп чыкты!  Хәйдәрнең шул вакытта куанулары хәзер дә хәтердә. Мине күргәч ул еш кына «коткаручым»  дип дәшә. Шул елгы экспедициянең соңгы көннәрен без Сверлау өлкәсенең Красноуфимск тирәләрендә төгәлләдек. Күрәсең, биредәге табигать, андагы кешеләр Хәйдәргә бик ошагандыр. Ул, институтны бетергәч,  Сверлау төбәгенә китеп барды. Мәдәният йорты белән җитәкчелек итте. Шуннан бирле биредәге татар концертларын, кичәләрен төп оештыручыларның берсе. Үзе дә матур итеп җырлый, сөйли. Инде ул хәзер татар дөньясында билгеле шәхес. «Татарстанның атказанган артисты». Дисклары да бар. Сверлауда Татарстан вәкиллеге оештырылганнан бирле ул вәкилнең урынбасары, төп көчләрнең берсе дә. Урал төбәгендәге мондый фидакарь,татарпәрвәр затларны тагын да телгә алырга мөмкин булыр иде: бергәләп бер үк йөкне — милләт йөген тартучы мондый шәхесләр шактый. Алга таба да алар киңәшеп, бер-берсен хөрмәт итеп, үзара каршылыкка кермичә яшәсеннәр, гамәл кылсыннар иде!

*        *        *

Татар дөньясы халкыбызның дүрттән бер өлеше генә яшәгән Татарстан белән генә чикләнми, ул зур, киң. Шуңа күрә безгә башка төбәкләр белән аралашып,  сөхбәтләшеп, үзара ярдәмләшеп яшәү сулаган һава, эчкән су кебек зарури. Шунсыз бинипая зур татар мәйданы кимиячәк һәм парчаланачак.

6. 02. 2013